КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 14 март г.Казань № 152

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 426 нчы карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 426 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 19 май, 356 нчы; 2016 ел, 16 июнь, 408 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 1.8.1 нче пункт өстәргә:

«1.8.1. Эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары белән яңа йөкләмәләрне билгели торган һәм элегрәк күздә тотылган йөкләмәләргә үзгәреш кертә торган, шулай ук эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасының норматив хокукый актларын бозган өчен җаваплылык билгели торган, җаваплылыкка үзгәреш кертә торган яки элегрәк билгеләнгән

җаваплылыкның гамәлен бетерә торган норматив хокукый актлар проектларына Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 7 мартындагы ТРЗ-14 нче номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә үткәрелә торган җайга салу йогынтысын бәяләү уздырылырга тиеш.»;

2.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Республика башкарма хакимият органының дәүләт теркәвенә алу өчен норматив хокукый акт җибәрү турындагы иярчен хатына кәгазь йөркечтә түбәндәге документлар теркәлә:

норматив хокукый актның республика башкарма хакимият органының юридик хезмәте җитәкчесе тарафыннан һәр битнең икенче ягына виза куела торган төп нөсхәсе;

норматив хокукый актның ике күчермәсе (дәүләт сере булып торган мәгълүматлары яки конфеденциаль характердагы мәгълүматлары булган норматив хокукый актларны җибәргән очракта, бер күчермә кертелә);

республика башкарма хакимият органы каршындагы иҗтимагый совет бәяләмәсе, әгәр дә дәүләт теркәвенә алу өчен башкарма хакимият органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан тикшерү үткәрелмичә бастырып чыгарыла (кабул ителә) алмаган норматив хокукый актлар составына керә торган норматив хокукый акт кертелсә;

тиешле вәкаләтле органнарның бу Кагыйдәләрнең 1.8 һәм 1.8.1 нче пунктлары белән билгеләнгән очракларда алынган бәяләмәләр;

республика башкарма хакимият органының юридик хезмәте җитәкчесе тарафыннан имза куелган һәм түбәндәгеләр бирелгән белешмә кәгазе:

норматив хокукый актны бастыру чыгару (кабул итү) нигезләмәләре;

хокук мөнәсәбәтләренең тиешле өлкәсен җайга сала торган норматив хокукый актлар турында белешмәләр һәм аларны быстырып чыгарылган (кабул ителгән) норматив хокукый актка туры китерү вакытлары турында мәгълүмат;

республиканың кызыксынучы башкарма хакимият органнары һәм башка дәүләт органнары белән норматив хокукый актны килештерү турында мәгълүматлар, әгәр дә мондый килештерү мәҗбүри булса;

норматив хокукый актка коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез экспертиза һәм җәмәгать экспертизасы үткәрү турында мәгълүматлар;

норматив хокукый акт әзерләүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат турында мәгълүматлар (телефон номерын күрсәтеп).

Иярчен хатта түбәндәгеләр булырга тиеш:

бу Кагыйдәләрнең 3.2.1 нче пункты белән күздә тотылган очракта, теркәлгән норматив хокукый актны «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында бастырып чыгару өчен түләү гарантиясе;

бу Кагыйдәләрнең 3.2.2 нче пункты белән күздә тотылган очракта, теркәлгән норматив хокукый актны татар теленә тәрҗемә итү гарантиясе.»;

3.3 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары дәүләт теркәвенә алынган көннән соң 10 көн эчендә рәсми бастырып чыгарылырга тиеш һәм алар, рәсми бастырып чыгарылган көннән соң 10 көн үткәч, үз көченә керә, әгәр дә актларның үзләрендә үз көченә керүенең башка тәртибе билгеләнмәсә.»;

3.4 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин